# Йоклау һәм төш күрү

الرؤى والمنامات

اللغة التترية

ALSARHAAN.COM

من آيات الله تعالى النوم وما فيه من منامات.

Аллаһның могҗизасыннан булып тора – ул да булса йоклау һәм төш күрү.

قال تعالى: ومن آياته منامكم بالليل والنهار وابتغاءكم من فضله إِنَّ فيِ ذَٰلِكَ لَأَيَاتٍ لِقَوْمٍ يَسْمَعُونَ

Аллаһ Раббыбыз әйтте: «Аллаһның могҗизасыннандыр төнге вә көндезге йокыларыгыз һәм Аллаһның фазыйләтләреннән кәсеп итүегез. Әлбәттә, бу эшләрдә игътибар белән тыңлаучыларга Аллаһуның кодрәтенә дәлилләр бар.»

وأول ما بدأ به النبي صلى الله عليه وسلم من الوحي الرؤيا الصادقة. لذا قال عليه الصلاة والسلام: رؤيا المؤمن جزء من ستة أربعين جزءا من النبوة.

Иң беренче итеп Пәйгамбәребезгә ﷺ турылыклы төшләр иңдерелгән. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Мөэминнең төше – кырык алты өлеш пәйгамбәрлекнең бер өлеше булып тора".

وكان رسول الله صلى الله عليه وسلم يعجبه الرؤيا الحسنة. وكان يهتم بشأنها.

Пәйгамбәребезгә яхшы төшләр ошап, Ул аларның мәгънәләренә игътибар бирә торган булган.

فعن سمرة قال: "كان النبي صلى الله عليه وسلم : إذا صلى صلاة أقبل علينا بوجهه فقال: من رأى منكم اللَيْلَةَ رؤيا؟ فان رأى احد قصها

Сәмурадан хәбәр ителә: Пәйгамбәребез ﷺ намаз укыганда безгә бите белән борылып: "Бүген төнлә кем төш күрде?,- дип сорады. Һәм берәрсе күргән булса, ул бу төшен сөйләп бирде"

والمنامات ثلاثة أقسام:

١- رؤيا صالحة : وهي بشرى من الله.

٢- رؤيا تحزين: وهي من الشيطان.

٣- ورؤيا مما يحدث المرء نفسه.

Төшләр өч төрле була:

1)Яхшы төш һәм ул Аллаһтан сөенеч.

2)Куркыныч яки борчый торган төш – монысы шәйтаннан.

3)Кеше мәшәкатьләре турында уйланып йөрү сәбәпле кергән төш.

فالرؤيا الصالحة بشرى.

Яхшы төш – ул сөенеч.

قال النبي صلى الله عليه وسلم:لمْ يَبْقَ مِنْ النُبُوَّةِ إلا المُبَشِّراتُ: الرؤيا الصالحة يراها المسلم أو تُرا لهُ و من احبّ ان تكون رؤياه صادقة فلْيصْدُق في يقظته

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:
"Пәйгамбәрлектән шатландыручы нәрсәләрдән кала башка нәрсә калмады, һәм ул – чын, яхшы төш. Аны мөселман кешесе күрер яки ул аңа иңдерелер. Һәм кем дә кем, төшенең чын, яхшы төш булуын теләсә, дөресен генә сөйләсен.

قال النبي ﷺ : "إذا اقترب الزمان لمْ تكدْ رؤيا المسلم تكذِبُ، و أصدقكم رؤيا أصدقكم

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Кыямәт көне якынайгач мөселманның төше ялган булмас. Һәм сездән иң рас төш күрүчеләр, сезнең арада иң дөрес булганнары".

والسُنة لمن رأى في منامه ما يحب أن يحمد الله عليها. وألا يُحدث بها إلا من يحب وأن يفسرها.

Кем дә кем яхшы, үзенә охшый торган төш күрсә, Аллаһны мактасын. Бу – сөннәт гамәлләрдән булып тора. Һәм шулай ук кешеләргә бары тик яхшы дип тапкан төшләрен генә сөйләсен.

وأما من رأى ما يكره فليتفل عن يساره ثلاث مرات. وليتعوذ بالله من شر مارأى ومن شر الشيطان الرجيم ثلاثا. وليتحول عن جنبه الذي كان عليه أو أن يقوم فيصلي ولا يخبر بها أحدا ولا يفسرها فإنها لن تضره.

Ә инде кем дә кем начар төш күрсә, өч тапкыр сулга таба төкереп куйсын, һәм бу төшнең начарлыгыннан һәм шәйтанның явызлыгыннан өч тапкыр Аллаһка сыенсын, һәм шулай ук икенче ягына борылып ятсын яки торып намаз укысын. Һәм берәүгә дә бу төш турында хәбәр итмәсен һәм бу төшне тәфсирләмәсен. Шул чагында бу төш аңа зыян итмәс.